# Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа-Иглай авыл җирлеге Иске Иглай авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР

«23» ноябрь 2024 ел № 13

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 23 ноябрендә узган:

«2025 елда Яңа Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай торак пунктында яшәүче һәм теркәлгән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан кала һәр балигъ булган кешедән, 2000 сум күләмендә алынган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);

- Иске Иглай торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү» .

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 42 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 24 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 22 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 2 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа-Иглай авыл җирлеге Иске Иглай авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
«2025 елда Яңа Иглай авыл җирлегенең Иске Иглай торак пунктында яшәүче һәм теркәлгән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан кала һәр балигъ булган кешедән, 2000 сум күләмендә алынган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);

- Иске Иглай торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү» .» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

2. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Х. Хәнәфиев

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы

вазыйфаларын башкаручы И.Х. Хәнәфиев